**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ АБДУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«20» май 2021 ел № 11

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 25 сентябрь «Иске Абдул авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе һәм Башкарма комитет вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш тәртибен раслау турында» 5 номерлы карары үз көчен югалткан дип тану хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге уставы нигезендә ТР Иске Абдул авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 25 сентябрендәге «Иске Абдул авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе һәм Башкарма комитет вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш тәртибен раслау турында» 5 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының мәгълүмат сайтында (https://tukay.tatarstan.ru/) урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Р.Х.Сафина